**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге КАРАРЫ**

2018 елның 24 августы 19№

2018-3

**Иске Камка авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 мартындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2009 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 381-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 5 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Иске Камка авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 мартындагы«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 1 бүлекнең 6 пунктындагы 30 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«стационар булмаган сәүдә объекты - вакытлыча корылган яисә вакытлыча төзелгән сәүдә объекты, инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташу (технологик тоташтыру) булуга яисә булмавына карамастан, җир кишәрлеге белән нык бәйләнмәгән, шул исәптән күчмә корылма;»

- 10 пунктта, 13 пунктның 2 пунктчасында, 36 пунктта, 64 пунктта, 73 пунктта, 86 пунктта «муниципаль заказ» сүзләрен «дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка җирлеге Уставында билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Камка авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе: Ф.Ә.Акберов

СОВЕТ СТАРОКАМКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ